

# Ибраһим Газиның “Йолдызлы малай” әсәрен йомгаклау.

## Сугышта балалар батырлыгы.

# Киңәшләр.

- Әдәпле һәм игътибарлы бул!
- Сүзеңне ачык һәм дөрес әйт!
- Иптәшләреңне хөрмәт ит!
- Башкаларны бүлдермә!







# Герой – пионерлар.



Леонид
Голиков



Зина
Портнова



Валя
Котик




Витя
Хоменко



Зоя
Космодемья
нская

# Районыбыз Геройлары.

- Булатов Василий
- Гарифуллин Габдулла
- Гыйлметдинов Гайфетдин
- Ибраһимов Хәбибулла
- Рәхимов Бакый
- Сабиров Хафиз

**1. « Немец, елмая-елмая, Илгизәргә таба килә иде. Малай шушы минутта үзенең хатасын аңлап алды. Күлмәген салып, ул бик ялгышкан, тик хәзер соң иде инде.»**

- 2. “Кешеләр шундый ябыкты, коры сөяккә калдылар. Бертуктаусыз кояш астында... Битләре кара көйде.”

- *3. “Немец солдаты, аны монда алып килгәндә, «кых!» дип муенын сызып күрсәтеп, малайны куркытырга теләгән иде. Әллә бу подвалда, чынлап та, кеше суялармы икән?»*

- **4. “Хатыннар балаларны үз артларына яшереп хәл алдыралар. Шулай итмәсәләр, бу галәмәткә бала-чага күптән егылган булыр иде инде.”**

- 5. “Кичке кояшның алтын тузаны коридорга сибелде. Свастикалы ишек тавышсыз гына ачылып китте. Бусагага абына-сөртенә, Илгизәр килеп чыкты.”

# “Авыл халкы пленда”.

- Илгизәр – ябык,зур күзләре генә утырып калган, иреннәре кипкән, тир ага.

- “Кыска муенлы, җан биздергеч тавышлы, юан аяклы, чекрәеп торган кургаш үткен күзле, симез үрдәктәй чайкалып, ары-бире йөренеп тора...”

- Җан биздергеч – куркыныч, коточкыч
- Кургаш - свинец

- “Илгизәр хатыннар артына ышыкланырга **хурлана**: **ир кеше** ич ул, **яше уникедә** генә булса да, **ир-заты**... Кайнар таш өстенә хәлдән таеп егылса егылыр, хатыннар артына яшеренмәс”.

- Ышыклану – яшерену
- Хурлану - оялу

# “Илгизәрнең хатасы”.







# “Илгизәр подвалда”.

- "Малайның күзләре зурайды..сулышы кысылды... тешләрен кысты да жылап жибәрде... бераз тынычланды... әллә бу подвалда  чынлап та, кеше суялар микән... йөрәге тарс-торс тибә...саташкан кешедәй, идәнгә канга карап торды да йөгереп барып ишекне тартты. Тәрәзәгә ташланды, сикерде, менде. Куллары чәнечкеле тимерчыбыкка кадалдылар... Илгизәр кире шуып төште. Хәле бетеп идәнгә утырды.”

# “Борчулы уйлар”.

- “... Әнкәсе белми дә кала инде. Сеңлесе дә... Үлмәс кебек, аны коткарырлар кебек. Әнкәсе йөгереп килер... Юк, әнкәсе килә алмас. Ул тимерчыбык белән чолганган лагерьда... Аны җибәрмәсләр... Кем коткарыр соң аны?”

# “Үзәк өзгеч тавыш”.



“Үрмәкүч төсле кара свастика төшергән зур ишек,Илгизәрне йотып, тавышсыз гына ябылды”.

Свастика – фашистларның символы, үлем

# Мәкальләр.

- Батыр бер үләр, куркак мең үләр.
- Батыр ярасыз булмас.
- Батыр үзе өчен туар, кеше өчен үләр.
- Батырлыкта- матурлык.
- Батыр үзе үлсә дә, исеме үлмәс.
- Батыр егет- ил күрке.

# Өй эше.

- 1. Ибраһим Газиның сугышка багышланган башка берәр әсәрен укырга.
- 2. Интернеттан Бөек Ватан сугышы, геройлары турында мәгълүмат тупларга.
- 3. Бөек Ватан сугышына карата рәсем ясарга.



# Дәрес тәмам. Сау булыгы